| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** с. Старое Дрожжаное **КАРАР**

20 февраль 2023 ел № 31/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2022 елның 28 декабрендәге 562-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 32 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чокалы авыл җирлегендә Иске Чокалы авыл җирлеге Советының 06.06.2022 ел, № 21/1 карары ( 16.12.2022 ел, №28/2 редакциясендә) белән расланган Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә 13.4 статьяның 3 пунктын яңа редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«3. Җирлекнең хисап финанс елында бурыч алуларының гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның һәм җирлекнең бурыч йөкләмәләрен хисап финанс елы ахырында барлыкка килгән калдыклар күләменә каплау күләмнәренең гомуми суммасыннан артып китәргә мөмкин максатчан билгеләнеше булган юридик затлардан, Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларның балансльлыгын тәэмин итү чараларына яисә җирле бюджетларга башка дотацияләргә дотацияләр бирүгә аларны бирү шартларын билгеләү белән бирелгән ,шулай ук хисап финанс елының соңгы эш көненнән соң җирле бюджетка күчерелгән хисап финанс елы керемнәре күләменә, шул исәптән йомгаклау әйләнешләрен уздыру тәртибендә дә.

Хисап елында җирлекнең бурыч алуларының гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның һәм, әлеге

пунктның беренче абзацында каралган мөмкин булган артымнарны исәпкә алып, җирлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәренең гомуми суммасыннан артып киткән очракта, агымдагы елның 1 гыйнварына барлыкка килгән җирле бюджет акчалары әлеге күрсәтелгән суммада җыелган агымдагы финанс елына бурычлар алуның чик күләмен киметеп, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96 статьясында каралган максатларга юнәлдерелергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртип нигезендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Чүпрәле авыл җирлеге
Башлыгы Урынбасары: Р.Д.Низамов